«4. Муниципаль хезмәткәрләргә бирелә торган тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгын билгеләү һәм аларга федераль законнарда, әлеге Кодекста һәм муниципаль берәмлекләр уставларында каралган башка гарантияләрне билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажына «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 25 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән вазыйфаларны биләү чорлары, шулай ук «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясындагы 2 өлеше нигезендә дәүләт граждан хезмәте стажына керә торган (исәпләнә торган) вазыйфалар биләү чорлары керә (исәпләнә).».



**6 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә файдаланылмаган еллык түләүле отпусклары яисә шушы отпускларның өлешләре булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең алардан файдалану хокукын, шулай ук файдаланылмаган еллык түләүле отпусклар яисә шушы отпускларның өлешләре өчен акчалата компенсация алу хокукын саклап калырга.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 21 апреле
№ 22-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 268. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле «б$^4$» пунктчасын өстәргә:

«б$^4$) депутат үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы

йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмаганда яисә үз вакытында тапшырмаганда;»;

б) 4 пунктта «законнарда каралган» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексында каралган» сүзләренә алмаштырырга;

2) $10^1$ статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат ел саен финанс хисабы елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә (алга таба әлеге статьяда – Комиссия) үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш.»;

б) 3 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) белешмәләр тапшырыла торган елга кадәрге календарь ел дәвамында (алга таба – хисап чоры) үзе тарафыннан, хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ булмаган балалары тарафыннан җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алуга кагылышлы һәр башкарылган алыш-биреш буенча, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, үзенең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында һәм бу алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.»;

3) $10^4$ статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчасында «җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алу буенча чыгымнар турында, әгәр алыш-биреш суммасы



депутатның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда гомуми кеременнән артса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары» сүзләрен «чыгымнар» сүзенә алмаштырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $10^5$ статья өстәргә:

«$10^5$ статья. **Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу максатларында депутатларга бирелә торган йөкләмәләр**

Депутат «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарында билгеләнә торган нигезләр булганда һәм тәртиптә, үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында Комиссиягә хәбәр итәргә, шулай ук мондый конфликтны булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 21 апреле
№ 23-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 269. Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек башкаручы субъектлар, әлеге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керүче оешмалар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте өлкәсендә хокукый җайга салу**

1. Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте өлкәсендә хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга нигезләнә һәм «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.
2. Әлеге Закон составында спирт булган азык-төлек продукциясе, алкоголь продукциясе һәм тәмәке әйберләре җитештерүгә бәйле мөнәсәбәтләргә карата кулланылмый.

**3 статья. Төп терминнар һәм төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:
1) Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте (алга таба шулай ук – сәнәгать сәясәте) – Россия Федерациясендә



сәнәгать сәясәте максатларын, бурычларын һәм принципларын исәпкә алып, Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәтен формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу кысаларында Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү максатларында Татарстан Республикасының сәнәгать потенциалын үстерүгә, конкурентлыкка сәләтле сыйфатлы продукция җитештерүне тәэмин итүгә, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга, сәнәгатьне нисбәтле һәм тотрыклы үстерүгә юнәлдерелгән хокукый, икътисадый, социаль, оештыру, мәгълүмати, белем бирү һәм башка чаралар комплексы;
2) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары – Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар;
3) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чаралары – Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керә торган оешмалар тарафыннан башкарыла торган һәм сәнәгать сәясәте максатларына ирешүгә юнәлдерелгән хокукый, икътисадый һәм оештыру характерындагы гамәлләр;
4) импорт алмаштыру – аерым товарлар импортын Россия җитештерүчеләре тарафыннан шундый ук товарлар яисә аларның конкурентлыкка сәләтле аналогын чыгару юлы белән киметү яисә туктату;
5) индустриаль (сәнәгать) парк – сәнәгать җитештерүен яисә сәнәгать җитештерүен модернизацияләүне булдыру өчен билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән идарәче компания – коммерцияле яисә коммерциягә карамаган оешма тарафыннан идарә ителә торган сәнәгать инфраструктурасы объектлары җыелмасы;
6) сәнәгать кластеры – территориаль якынлык һәм функциональ бәйлелек нигезендә сәнәгать өлкәсендәге мөнәсәбәтләргә бәйле һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күрсәтелгән өлкәдәге эшчәнлек субъектлары җыелмасы;
2. Әлеге Законда кулланыла торган башка терминнар һәм төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

4 статья. **Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтенең максатлары һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтенең система барлыкка китерү максатлары продукциянең конкурентлыкка

сәләтен һәм сәнәгатьнең техник дәрәҗәсен арттырудан, инновацион продукцияне һәм югары технологияләрне эчке һәм тышкы базарларга чыгаруны тәэмин итүдән, импорт продукциясен алмаштырудан һәм сәнәгатьне инновацион актив сәнәгать җитештерүе нигезендә тотрыклы үсеш баскычына күчерүдән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасы компетенциясе чикләрендә сәнәгать сәясәте бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) эшкәртү тармаклары продукциясен җитештерүнең чимал табу тармаклары белән чагыштырганда алданрак үсешен тәэмин итү, продукциянең, технологияләрнең, материалларның яңа төрләрен эшләү, булган фәнни-техник потенциалдан һәм фундаменталь, гамәли тикшеренүләрнең яңа нәтиҗәләреннән файдалану;

2) эчке һәм тышкы базар ихтыяҗын өйрәнү нигезендә җитештерүне оештыру һәм кооперацияне, шул исәптән трансмилли кооперацияне үстерү;

3) Татарстан Республикасының сәнәгать комплексында кластер берәмлекләрен нәтиҗәле формалаштыру һәм үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру, сәнәгать комплексы урнашуның региональ, аерым алганда территориаль үзенчәлекләрен истә тоту;

4) сәнәгатьне тотрыклыландыруның һәм икътисадый үстерүнең барлык ресурсларын бәяләү һәм алардан тулысынча файдалану;

5) конкурентлык мохитен үстерү, икътисадый эшчәнлекнең тигез һәм алдан билгеле шартларын тудыру;

6) импортны алмаштыруның формалашып килүче эзлеклелегенә ярдәм итү юлы белән икътисадый үсешне кызыксындыру;

7) Россия базарына һәм халыкара базарларга юнәлеш тоту;

8) экспортка ярдәм итүгә һәм эчке базарның яңа сегментларын үзләштерүгә юнәлдерелгән кредит һәм лизинг институтлары булдыруга ярдәм итү;

9) җитештерү баскычларын һәм аерым технологияләрне модернизацияләү, аларның структурасын үзгәртеп кору;

10) техник регламентларны үтәүгә дәүләт контролен (күзәтчелеген) көчәйтү һәм продукциянең заманча сыйфат системаларын, сертификациясен гамәлгә кертү;

11) икеләтә билгеләнештәге технологияләрне үстерү, моңа яңа материаллар барлыкка китерү технологияләре, мәгълүмат технологияләре, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге технологияләр һәм башка технологияләр керә;

12) өстәлгән бәясе югары булган эшкәртү тармаклары продукциясе өлешен даими арттырып, экспортны диверсификацияләү;



13) фән, мәгариф һәм сәнәгать интеграциясе, фәнни, югары технологияле, ресурсларны сакчыл тотучы, имин һәм экологик чиста производстволарны үстерү.

5 статья. **Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашучылар**

Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашучылар – Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары, әлеге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керүче, шул исәптән сәнәгать өлкәсендә эш бирүчеләрне берләштерүче коммерциягә карамаган оешмалар.

6 статья. **Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) сәнәгать сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итә;

2) сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын кабул итә;

3) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган фәнни техник һәм инновацион программаларны һәм проектларны, шул исәптән Татарстан Республикасы фәнни оешмалары тарафыннан, эшләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыра;

4) федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы белән сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыру турында килешүләр төзи;

5) сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә, шул исәптән сәнәгать өлкәсендә стратегик планлаштыру документлары проектларын эшләү буенча, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарын билгели;

6) федераль законнарда, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән кызыксындыру чараларын индустриаль (сәнәгать) паркларга һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләренә, сәнәгать кластерларына, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларына бирү максатларында аларга карата өстәмә таләпләр билгели;

7) Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларга һәм сәнәгать кластерларына Татарстан Республикасы мөлкәте һәм бюджеты акчалары исәбеннән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын бирү тәртибен раслый, шулай ук бюджет акчаларын максатчан кулланылуны тикшереп тора;

8) сәнәгатьне үстерүнең дәүләт фондларын төзи;

9) Татарстан Республикасының сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасы сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган акчалар исәбеннән финанс ярдәме күрсәтү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләрен билгели;

10) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында сәнәгать сәясәте өлкәсендә координацион һәм киңәшмә органнары төзү турында карарлар кабул итә, аларның составын һәм алар турындагы нигезләмәләрне раслый;

11) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына ел саен Татарстан Республикасында сәнәгать торышы һәм үсеше турында, Татарстан Республикасында сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашыру хакында доклад тапшыра;

12) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә сәнәгать сәясәте өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Сәнәгать өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы (алга таба – сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган):

1) федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

2) сәнәгать сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының норматив хокукый актларын әзерли;

3) Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать үсешенә ярдәм итә торган чараларны гамәлгә ашыра;

4) сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында кабул ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын әзерли һәм аларны башкаруны тәэмин итә;

5) Татарстан Республикасында сәнәгать торышын мониторинглауны гамәлгә ашыра һәм кирәкле мәгълүмат соратып ала, Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының тотрыксыз үсеше куркынычын кисәтү чараларын күрә;

6) сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне кызыксындыру буенча тәкъдимнәр әзерли, Татарстан Республикасында сәнәгать торышы һәм үсеше турында, Татарстан Республикасында сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашыру хакында еллык доклад әзерли һәм аны бастырып чыгара;



7) Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларны һәм сәнәгать кластерларын төзү һәм үстерү мәсьәләләре буенча сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

8) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы оешмалары белән берлектә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтүдә катнаша;

9) сәнәгать кластерларына, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларына карата әлеге Законда, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән кызыксындыру чараларын куллану максатларында шушы сәнәгать кластерларының, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән өстәмә таләпләргә туры килүен раслый;

10) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасы территориясендә булган хезмәт ресурслары һәм яңа эш урыннарын булдырудагы ихтыяҗлар турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә;

11) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының региональ һәм регионара хезмәттәшлеген үстерүгә, сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары белән башка оешмалар арасында җитештерү һәм сәүдә багланышлары булдыру һәм үстерү юлы белән сәнәгать кооперациясен үстерүгә ярдәм итә;

12) үз вәкаләтләре чикләрендә федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, халыкара оешмалар һәм чит илләрнең административ-территориаль берәмлекләре белән сәнәгать сәясәте өлкәсендә хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

13) үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы территориясендә оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең эшчәнлеге һәм үсеше мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлек итә;

14) федераль башкарма хакимият органнары белән Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыру турында килешүләр әзерли һәм аларга имза салуны тәэмин итә;

15) дәүләт мәгълүмати сәнәгать системасы операторына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән составта һәм тәртиптә мәгълүмат бирүне тәэмин итә;

16) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән үзенә йөкләнгән сәнәгать өлкәсендәге башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

7 статья. **Сәнәгать сәясәте өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнары федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлекләр уставлары нигезендә муниципаль берәмлекләр территорияләрендә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашырырга хокуклы.

8 статья. **Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чаралары**

Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру аның субъектларына түбәндәге дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме;

2) импорт алмаштыруны, сәнәгать кооперациясен үстерүгә ярдәм итү;

3) сәнәгать өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлеккә һәм инновация эшчәнлегенә ярдәм итү;

4) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына аларның кадрлар потенциалын үстерү өлкәсендә ярдәм күрсәтү;

5) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына тышкы икътисадый эшчәнлек өлкәсендә ярдәм итү;

6) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына мәгълүмат-консультация ярдәме күрсәтү;

7) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына аларның Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының дәүләт программаларында катнашу мәсьәләләрендә ярдәм итү;

8) ярдәм итүнең Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка чаралары.



9 статья. **Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме**

Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме Россия Федерациясе законнарында, Федераль законда, шулай ук Татарстан Республикасы вәкаләтләре кысаларында әлеге Законда, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законында, «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган рәвешләрдә сәнәгатьнең аерым тармакларының торышын исәпкә алып күрсәтелә.

10 статья. **Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары**

1. Татарстан Республикасы тарафыннан фонд яисә автоном учреждение оештыру-хокукый рәвешендә төзелгән дә, төзелә торган да, йә Татарстан Республикасының сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керә торган оешмалар белән берлектә фонд оештыру-хокукый рәвешендә төзелә торган Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтәләр.

2. Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары Татарстан Республикасының сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керә торган оешмалар була. Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондын гамәлгә куючының вәкаләтләрен һәм функцияләрен Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты башкара, ул гамәлгә куючы вәкаләтләренең һәм функцияләренең өлешен сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле органга тапшырырга хокуклы.

3. Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары мөстәкыйль рәвештә яисә Татарстан Республикасының сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керә торган оешмалар белән берлектә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Россия Федерациясе законнарына туры килә торган теләсә кайсы рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән финанс ярдәме күрсәтәләр.

4. Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү дәүләт фондлары финанс ярдәме белән беррәттән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына ярдәм итүнең Федераль законда һәм әлеге Законда каралган башка төрләрен күрсәтергә хокуклы.

11 статья. **Татарстан Республикасы исеменнән махсус инвестиция контракты**

1. Татарстан Республикасы исеменнән махсус инвестиция контракты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан төзелә.

2. Әгәр башкасы Федераль законда каралмаган булса һәм махсус инвестиция контрактының асылына каршы килмәсә, махсус инвестиция контрактына карата Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының инвестиция эшчәнлеге турындагы законнарының нигезләмәләре кулланыла.

3. Махсус инвестиция контрактының ягы булган инвесторга һәм (яисә) махсус инвестиция контрактында күрсәтелгән башка затларга карата муниципаль хокукый актларда каралган сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашыру максатларында махсус инвестиция контрактының яклары Татарстан Республикасы белән беррәттән муниципаль берәмлекләр булырга мөмкин.

4. Махсус инвестиция контрактын Татарстан Республикасы тарафыннан төзү тәртибе, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән махсус инвестиция контракты төзү тәртибен һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган типлаштырылган рәвешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

12 статья. **Индустриаль (сәнәгать) парклар**

1. Индустриаль (сәнәгать) парклар, индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләре аларга карата сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллану максатларында индустриаль (сәнәгать) паркка һәм индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән төп таләпләргә җавап бирергә тиеш.

2. Индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә һәм сәнәгать инфраструктурасы объектларыннан файдаланучы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына карата сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллану



максатларында индустриаль (сәнәгать) паркка һәм индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә карата өстәмә таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

3. Индустриаль (сәнәгать) паркның һәм индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенең индустриаль (сәнәгать) паркка, индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә карата Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендәге вәкаләтле органы әлеге статьяда билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаган индустриаль (сәнәгать) паркларның, индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләренең реестрын алып бара һәм сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына әлеге реестрдан өземтәләр бирә. Күрсәтелгән реестрны алып бару тәртибен әлеге вәкаләтле орган билгели.

13 статья. **Сәнәгать кластерлары**

1. Сәнәгать кластерларына карата әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллану, сәнәгать кластерын үстерүне методик, оештыру, эксперт-аналитик һәм мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешма төзү һәм сәнәгать кластерының, сәнәгать кластерының махсуслаштырылган оешмасының Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән өстәмә таләпләргә туры килүе шарты белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Сәнәгать кластерының һәм сәнәгать кластерының махсуслаштырылган оешмасының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән өстәмә таләпләргә туры килүен раслауны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.

3. Сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаган сәнәгать кластерларының һәм сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларының реестрын алып баруны

гамәлгә ашыра. Күрсәтелгән реестрны алып бару тәртибен әлеге вәкаләтле орган билгели.

14 статья. **Дәүләт мәгълүмати сәнәгать системасы белән хезмәттәшлек**

1. Сәнәгать сәясәтен формалаштыруда катнашучыларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү, алар арасындагы нәтиҗәле хезмәттәшлекне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән составта һәм тәртиптә дәүләт мәгълүмати сәнәгать системасы операторына мәгълүмат бирүне тәэмин итә.

2. Үзләренә карата әлеге Законда каралган сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне кызыксындыру чаралары кулланылган йә шушы чараларны куллануга дәгъва итүче сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле органга дәүләт мәгълүмати сәнәгать системасына кертү өчен кирәкле мәгълүматны, файдалануы федераль законнар белән чикләнгән мәгълүматтан тыш, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырырга тиеш.

15 статья. **Сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашырганда фәннитехник эшчәнлеккә һәм инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү**

Сәнәгать сәясәтен гамәлгә ашырганда фәнни-техник эшчәнлеккә һәм инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына дәүләт оборонасын һәм иминлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган сәнәгать тармакларында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру барышында башкарыла торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технология эшләрен финанслауга субсидияләр бирү;

2) Татарстан Республикасы катнашындагы хуҗалык җәмгыятьләрендә йә Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмаларда Татарстан Республикасының тиешле хуҗалык җәмгыятендә катнашучы (акционер) яисә коммерциягә карамаган оешманы гамәлгә куючы буларак хокукларын гамәлгә ашыру юлы белән инновация эшчәнлеген кызыксындыру;

3) инновацион продукциягә ихтыяҗны, шул исәптән дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә нормалар билгеләү аша кызыксындыру;



4) сәнәгать производстволарының экологик иминлек дәрәҗәсен, шул исәптән иң яхшы технологияләрдән файдалану ярдәмендә, күтәрү буенча проектларны гамәлгә ашыруда инжиниринг хезмәтләрен күрсәткәндә инновация эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга финанс ярдәме күрсәтү;

5) фәнни, фәнни-техник эшчәнлекне һәм инновация эшчәнлеген башкарганда сәнәгать өлкәсендәге субъектларның эшчәнлеген координацияләү өчен һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрләре субъектлары арасындагы кооперация өчен шартлар тудыру;

6) сәнәгать продукциясен җитештерүне булдыру яисә аны күпләп җитештерү эшчәнлеген фән, техника һәм технологияләрне үстерүнең өстенлекле юнәлешләренә яисә критик технологияләргә карый торган интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен производствога кертү юлы белән кызыксындыру;

7) сәнәгать җитештерүендә файдаланып булган иң яхшы технологияләрне куллану буенча эшчәнлекне кызыксындыру.

16 статья. **Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына кадрлар потенциалын үстерү өлкәсендә ярдәм**

Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына кадрлар потенциалын үстерү өлкәсендә ярдәм түбәндәгечә күрсәтелергә мөмкин:

1) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары хезмәткәрләре өчен өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга мәгълүмат һәм консультация ярдәме күрсәтеп;

2) күрсәтелгән субъектларның хезмәткәрләре өчен өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм теоретик белемнәрнең тәҗрибә күнекмәләре һәм осталыклары белән бергә үрелгән тәэмин итүче оешмаларны төзүдә катнашучы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтеп;

3) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына алар тарафыннан өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеге гамәлгә ашырылганда ярдәм күрсәтүгә бәйле башка чаралар күреп.

17 статья. **Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына тышкы икътисадый эшчәнлек өлкәсендә ярдәм**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына түбәндәгечә ярдәм күрсәтә алалар:

1) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән сәнәгать продукциясен чит ил базарларына чыгаруга Татарстан Республикасы вәкиллекләре институтын җәлеп итү юлы белән булышлык күрсәтеп;

2) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән сәнәгать продукциясе экспортын гамәлгә ашыручы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары өчен Таможня берлегенең таможня законнары һәм таможня эше турында Россия Федерациясе законнары нигезендә уңай шартлар тудырып;

3) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән сәнәгать продукциясе экспортын гамәлгә ашыручы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәмен һәм мөлкәткә кагылышлы булышлык күрсәтеп;

4) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән сәнәгать продукциясе экспортын гамәлгә ашыручы сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына ярдәм итүнең башка чараларын башкарып.

18 статья. **Импорт алмаштыру өлкәсендә сәнәгать сәясәте**

1. Сәнәгать өлкәсендә импорт алмаштыруны үстерү үзенең характеристикалары буенча импорттан кертелә торган аналогларына туры килә торган йә үзлекләре һәм сыйфаты буенча алардан яхшырак, конкуренциягә сәләтле сәнәгать продукциясен җитештерүне оештыру һәм арттыру өчен башкарыла торган чаралар комплексын гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

2. Импорт алмаштыруны үстерүгә юнәлдерелгән сәнәгать сәясәте үз эченә түбәндәгеләрне алырга мөмкин:

1) импортны алмаштыра торган продукцияне җитештерүче сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары өчен Татарстан Республикасы законнары нигезендә уңай шартлар тудыру чаралары;

2) импорттан кертелә торган продукциянең конкуренциягә сәләтле аналогларын җитештерүне Татарстан Республикасы территориясендә булдыру һәм үстерү өчен башкарыла торган сәнәгать эшчәнлеген финанс белән кызыксындыру чаралары;

3) Татарстан Республикасына импорттан кертелә торган, Татарстан Республикасында яисә Россия Федерациясе субъектларында җитештерелми торган һәм җитештерелә алмаган һәм сәнәгать продукциясен җитештерү өчен кулланыла торган материалларга, чималга, комплект детальләренә, җиһазларга һәм технологияләргә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының ихтыяҗын турыдан-туры булмаган алмаштыруга яисә киметүгә ярдәм чаралары;



4) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының производство ихтыяҗлары өчен комплект детальләренең бер урында җитештерелүен арттыру чаралары.

3. Сәнәгатьтә импорт алмаштыруны үстерү чараларын гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

19 статья. **Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына мәгълүмат-консультация ярдәме**

Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан мәгълүмат-консультация ярдәме шул исәптән түбәндәгечә күрсәтелергә мөмкин:

1) сәнәгать продукциясен җитештерү өчен кирәкле икътисадый, хокукый, җитештерү-технологик мәгълүматны һәм маркетинг өлкәсендәге мәгълүматны үз эченә алган каталоглар, белешмәлекләр, бюллетеньнәр нәшер итүне һәм (яисә) белешмәләр базаларын, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайтлар алып баруны финанслау аша;

2) күргәзмәләр, ярминкәләр, конференцияләр (шул исәптән халыкара) үткәрүне оештыру яисә аларны үткәрүдә ярдәм итү аша;

3) ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендәге программалар материалларыннан кала башка мәгълүмат-реклама материалларын урнаштыру яисә аларны урнаштыруда ярдәм итү аша.

20 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 21 апреле
№ 24-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 270. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 6 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

**«Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья. Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба – Федераль закон) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендәге вәкаләтләрен билгели, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуының аерым мәсьәләләрен җайга сала.

2 статья. **Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

1. Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Федераль закон, Россия Федерациясенең



башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Законда кулланылган төп төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлыкның максатлары һәм принциплары**

1. Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлыкның максатлары булып Татарстан Республикасы икътисадына хосусый инвестицияләр җәлеп итү, Татарстан Республикасының коммуналь, транспорт, социаль һәм башка инфраструктурасын үстерү өчен матди ресурсларны һәм финанс ресурсларын туплау, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең һәркем файдалана алырлык булуын һәм аларның сыйфатын күтәрүне тәэмин итү тора.

2. Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык түбәндәге принципларга нигезләнә:

1) дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләрдән тыш, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы;

2) конкуренцияне тәэмин итү;

3) дискриминация булмау, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү төзегән якларның хокуклары бертигез булу һәм аларның закон каршында тигез хокуклы булуы;

4) дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү төзегән якларның килешү йөкләмәләрен намуслы үтәве;

5) ихтимал булган куркынычларны һәм йөкләмәләрне дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү төзегән яклар арасында гадел бүлү;

6) дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне төзү иреге.

4 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) Татарстан Республикасы исеменнән гавами партнер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын билгели;

2) Федераль законның 17 статьясындагы 2 өлешендә, әлеге Законның 5 статьясында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру-

чы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгели;

3) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләр реестрын алып бару тәртибен билгели;

4) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда ведомствоара хезмәттәшлек регламентын раслый;

5) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торса йә Татарстан Республикасы катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылса (Россия Федерациясе катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылган очраклардан тыш), дәүләти-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул итә, шул исәптән дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу рәвешен билгели;

6) Федераль законда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты дәүләти-хосусый партнерлык проектын Федераль законның 9 статьясындагы 2 – 5 өлешләре нигезендә аның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына җибәрергә хокуклы.

5 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләре**

Вәкаләтле орган:

1) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне йә Татарстан Республикасы катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашырганда (Россия Федерациясе катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылган очраклардан тыш) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеген ведомствоара координацияләүне тәэмин итә;

2) әгәр дәүләти-хосусый партнерлык проектын эшләү инициаторы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булса, әлеге проектны гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимнәрне алдан карауны гавами партнер белән берлектә оештыра;

3) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык проектының нәтиҗәлелеген



бәяли һәм Федераль законның 9 статьясындагы 2 – 5 өлешләре нигезендә әлеге проектның чагыштырма өстенлеген билгели;

4) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык килешүен төзү хокукына конкурслар уздыру өчен конкурс документациясен гавами партнер белән килештерүне гамәлгә ашыра;

5) дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең гамәлгә ашырылуына мониторинг ясый;

6) дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру барышында гавами партнерларның һәм хосусый партнерларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауда булышлык күрсәтә;

7) дәүләти-хосусый партнерлык турында төзелгән килешүләр реестрын алып баруны гамәлгә ашыра;

8) әгәр килешүдә Татарстан Республикасы гавами партнер буларак катнашса, дәүләти-хосусый партнерлык турында төзелгән килешүләр турындагы мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итә;

9) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән федераль башкарма хакимият органына килешү йөкләмәләре буенча Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүнең йә Татарстан Республикасы катнашында уртак конкурс уздыру нигезендә төзелгән килешүнең гамәлгә ашырылуына ясалган мониторинг нәтиҗәләрен тапшыра;

10) Федераль законда, башка федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

6 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне әзерләү, төзү, үтәү һәм туктату тәртибе**

Дәүләти-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында тәкъдимне әзерләү, аның вәкаләтле орган тарафыннан каралуы, дәүләти-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул итү, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү төзү, үтәү һәм туктату Федераль закон нигезендә башкарыла.

7 статья. **Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу рәвешләре**

1. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә финанс, мөлкәт рәвешләрендә, мәгълүмат-консультация ярдәме

рәвешендә һәм законнарга каршы килми торган башка рәвешләрдә түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

1) дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү объектының хосусый партнер тарафыннан төзелүен, аннан файдалануны һәм (яисә) аңа техник хезмәт күрсәтүне Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү хисабына финанслау;

2) хосусый партнерга дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү объекты урнашкан йә төзелә торган һәм (яисә) дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүдә каралган эшчәнлекнең хосусый партнер тарафыннан гамәлгә ашырылуы өчен кирәкле җир кишәрлекләрен җир законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә торглар уздырмыйча гына арендага бирү;

3) хосусый партнерга Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез һәм (яисә) күчемле мөлкәтне Татарстан Республикасы законнары нигезендә ышанычлы идарәгә, аңа хуҗа булуга һәм (яисә) аннан файдалануга тапшыру;

4) хосусый партнерга дәүләти-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле икътисадый, хокукый, производство-технологиягә кагылышлы мәгълүматны урнаштыру өчен региональ мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен бирү;

5) хосусый партнерга дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү буенча җитештерелә торган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне тәкъдим итү өчен күргәзмәләр, форумнар һәм башка (шул исәптән халыкара) чаралар үткәрүдә һәм катнашуда булышлык күрсәтү;

6) башка ысуллар белән.

2. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуы бер яки берничә рәвештә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

8 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүнең үтәлешен тикшереп тору**

1. Гавами партнер хосусый партнерның дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү шартларын үтәвен, шул исәптән килешү объектын проектлау, төзү срокларына сыешуын, килешү объектын төзүне финанславын, килешү объектының техник-икътисадый күрсәткечләренең килешүдә каралган техник-икътисадый күрсәткечләргә туры килүен, килешүдә каралган эшчәнлекнең гамәлгә ашырылуын, килешү объектының килешүдә каралган максатларда файдаланылуын, шулай ук вәкаләтле органның уңай бәяләмә бирүе өчен нигез булган проект нәтиҗәлелеге критерийлары күрсәткечләренә һәм чагыштырма өстенлеге күрсәткечләренә ирешүен тикшереп тора.

2. Гавами партнер дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү үтәлешен, шул исәптән хосусый партнерның дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү шартларының үтәвен, федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә тикшереп тора.

3. Хосусый партнер тарафыннан дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү шартларының үтәлешен тикшерүдән алынган нәтиҗәләр тикшерү нәтиҗәләре турындагы акт белән рәсмиләштерелә.

4. Тикшерү нәтиҗәләре турындагы акт мондый акт төзелгән көннән алып биш көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә гавами партнерның рәсми сайтына урнаштырылырга тиеш. Күрсәтелгән актны карау мөмкинлеге дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүнең гамәлдә булу срогы дәвамында һәм килешү вакыты чыккан көннән соң өч ел дәвамында тәэмин ителә.

9 статья. **Коллегиаль киңәшмә орган**

Дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерүнең төп юнәлешләрен билгеләү һәм Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерүгә юнәлтелгән башка мәсьәләләрне хәл итүне Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләр биргән Татарстан Республикасында инвестиция климатын яхшырту буенча коллегиаль киңәшмә орган гамәлгә ашыра.».

**2 статья**

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән килешүләргә карата шул Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләре (әлеге Закон үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциядә) кулланыла. Мондый килешүләр нинди шартларда төзелгән булса, шул шартларда аларның гамәлдә булу срогы тәмамланганчы гамәлдә була.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай

ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын эшләүне һәм кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 23 апреле
№ 25-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 271. «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 1999, № 8 (I өлеш); 2002, № 12 (II өлеш); 2003, № 8; 2006, № 2 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3), түбәндәге эчтәлекле дүртенче өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт флагы гомуми белем бирү оешмалары биналарына, милек рәвешләренә карамастан, даими элеп куела йә даими рәвештә аларның территорияләрендә урнаштырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 23 апреле
№ 26-ТРЗ



# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 272. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унҗиденче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унҗиденче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2015 елгы эшчәнлеге турында хисап.
4. «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 213-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 189-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
6. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 190-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
7. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 191-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
8. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 192-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

9. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында» 205-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

10. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 178-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

11. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 201-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

12. «Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 185-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

13. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 217-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 221-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 34 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 218-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 210-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 216-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм $8^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 203-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 215-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).



20. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 164-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

21. Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2015 елгы эше турында хисап.

22. «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарын гамәлгә куючылар – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасындагы шартнамәләр турында – «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарын гамәлгә куючылар вәкаләтләренең бер өлешен «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына бирү турында.

23. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

24. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 151 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

25. «Россия Федерациясе Гаилә кодексына һәм Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 233 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

26. «Россия Федерациясе субъектлары иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 984349-6 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында.

27. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1006969-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чараларының велосипедта йөрүчеләр өчен полосалар, велосипедта һәм җәяү йөрүчеләр өчен юллар буенча хәрәкәте, шулай ук күрсәтелгән полосаларда туктаган һәм туктап торган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына төзелеш объектларында чит ил эшче көчләрен законсыз җәлеп итүне һәм алардан файдалануны булдырмау максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 1015753-6 номерлы федераль закон проекты турында (заказчы (төзүче) яисә подрядчы (генераль подрядчы) функцияләрен гамәлгә ашыручы йә Россия Федерациясендә төзелеш объектларын башкача тикшереп торучы затларның мондый объектларда чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның законсыз булуы һәм законсыз хезмәт эшчәнлеге өчен административ җаваплылыгын билгеләү хакында).

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1013569-6 номерлы федераль закон проекты турында (яктылыкны үткәрүге тәгәрмәчле транспорт чараларының иминлеге хакындагы техник регламент таләпләренә туры килми торган пыялаларны транспорт чараларына куйган өчен җаваплылык билгеләү турында).

30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1017410-6 номерлы федераль закон проекты турында (19.77 статьяда каралган хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тарту вакытын арттыру, шулай ук күрсәтелгән хокук бозулар буенча административ тикшерүне үткәрү мөмкинлеген билгеләү хакында).

31. «Россия Федерациясенә Кырым Республикасын кабул итүгә һәм Россия Федерациясе составында яңа субъектлар — Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре төзелүгә бәйле рәвештә мәгариф өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 1010317-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Кырым Республикасы оешмаларының мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын һәм укуны тәмамлаучыларга белем алу турында документлар бирү хокукын регламентлый торган рөхсәт бирү документларының гамәлдә булуын тану срокларын 2018 елның 1 сентябренә кадәр озайту өлешендә).

32. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.



33. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 32 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының — Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

34. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 50 статьясына һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль законның 154 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 1004120-6 номерлы федераль закон проекты хакында (муниципаль район белән авыл җирлекләре арасында муниципаль мөлкәт бүлешү тәртибен ачыклау өлешендә).

35. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 16 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1000387-6 номерлы федераль закон проекты турында (граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт узуга бәйле чикләүләр өлешендә).

36. «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» Федераль законның 47 статьясына үзгәреш кертү хакында» 993118-6 номерлы федераль закон проекты турында (торак фондын техник исәпкә алу өлкәсендә норматив хокукый актларның гамәлдә булуын саклап калу өлешендә).

37. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 38 һәм 44 статьяларына һәм «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мәскәү өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

38. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 136 статьясына үзгәреш кертү хакында» 997875-6 номерлы федераль закон

проекты турында» (отпуск өчен түләү срокларын төгәлләштерү өлешендә).

39. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Хакасия Республикасы Югары Советының закон чыгару инициативасы турында.

40. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 статьясына һәм 14.53 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карачай-Черкес Республикасы Халык Собраниесенең (Парламентының) закон чыгару инициативасы турында (насвай, суыра торган тәмәкене (снюс) күпләп яисә ваклап, шул исәптән балигъ булмаганнарга, саткан өчен җаваплылыкны катгыйландыру өлешендә).

41. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^{3}$ статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 1.3.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы хакында.

42. «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 987876-6 номерлы федераль закон проекты турында (бурычлының Россия Федерациясеннән китүенә вакытлыча чикләү билгеләү мөмкинлеге өчен критерийларны төгәлләштерү хакында).

43. «Тиешле срокта суд эшчәнлегенә хокукны яисә тиешле срокта суд актын үтәүгә хокукны бозган өчен компенсация турында» Федераль законга дәүләт тарафыннан мөлкәти һәм (яисә) мөлкәти булмаган характердагы таләпләрнең үтәлешен күздә тотучы суд актын тиешле срокта үтәү хокукын бозган өчен компенсация билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1027679-6 номерлы федераль закон проекты турында.

44. «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында» 1037356-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

45. «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» 1037366-6 номерлы федераль закон проекты турында.

46. «Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнешен контрольдә тоту өлкәсендә һәм миграция өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1037367-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

47. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге $333^{38}$ статьясына үзгәреш кертү турында» 1037372-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең варисларын нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасын түләүдән азат итү өлешендә).

48. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1168-V ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 273. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп биш елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Кузина Виктория Евгеньевнаны;

Татарстан Республикасы Әлмәт суд районы буенча:
3 нче суд участогына – Вилданов Марат Зиннәт улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Хәлиуллина Венера Илшат кызын;

Татарстан Республикасы Минзәлә суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Ихсанов Айнур Данил улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Латы йпов Азат Өлфәт улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Яруллин Илнур Әнәс улын.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп ун елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Бөгелмә суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Латыйпов Ришат Үзбәк улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү суд районы буенча:
5 нче суд участогына – Җиһаншина Яна Демуриевнаны;

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Идел буе суд районы буенча:
9 нчы суд участогына – Гатауллина Динә Азат кызын.

3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары вәкаләтләре чоры 2016 елның 1 маеннан башлана.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1169-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 274. Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының 7[1] статьясы һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Такаева Наталия Григорьевнага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1170-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 275. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2015 елгы эшчәнлеге турында хисап хакында

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2015 елгы эшчәнлеге турында хисапны карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2015 елгы эшчәнлеге турында хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2015 елгы эшчәнлеге турында хисапны караганда, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутат берләшмәләре, депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәрне карау һәм кирәкле чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2015 елгы эшчәнлеге турында хисапны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми сайтына урнаштыруны тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1171-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 276. «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 213-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 213-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2016 елның 21 апрелендә 13.30 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2016 елның 21 апрелендә 14.30



сәгатькә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1172-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 277. «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 213-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 213-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1173-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 278. «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы законы хакында (213-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы законын (213-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1174-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 279. «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 189-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 189-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1175-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 280. «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (189-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (189-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1176-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 281. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 190-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 190-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1177-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 282. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (190-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (190-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1178-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 283. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 191-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 191-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1179-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 284. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (191-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (191-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1180-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 285. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 192-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 192-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектына төзәтмәләр кертү вакытын 2016 елның 10 маена кадәр озайтырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2016 елның 10 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1181-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 286. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында» 205-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында» 205-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1182-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 287. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (205-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (205-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1183-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 288. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 178-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 178-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1184-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 289. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (178-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (178-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1185-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 290. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 201-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 201-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1186-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 291. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (201-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (201-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1187-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 292. «Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 185-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 185-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1188-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 293. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 217-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр (хайваннар) дөньясы объектларының тиешле рөхсәттән башка әйләнеше өчен административ җаваплылык билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 217-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр

(хайваннар) дөньясы объектларының тиешле рөхсәттән башка әйләнеше өчен административ җаваплылык билгеләү хакында) беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1189-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 294. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (217-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (217-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1190-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 295. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 221-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 221-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1191-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 296. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (221-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (221-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1192-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 297. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 34 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 218-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Т.Г. Һадиев һәм Р.Р. Гайзатуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 34 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 218-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1193-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 298. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 34 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (218-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 34 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (218-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1194-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 299. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 210-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 210-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1195-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 300. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (210-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (210-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1196-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 301. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 216-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 216-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1197-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 302. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (216-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (216-5 номерлы проект) кабул итәргә.



2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1198-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 303. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм $8^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 203-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Прокофьев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм $8^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 203-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын кире кагарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1199-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 304. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 215-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 215-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2016 елның 21 маена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2016 елның 21 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1200-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 305. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 164-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Прокофьев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 164-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын кире кагарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1201-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 306. Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2015 елгы эше турында хисап хакында

Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2015 елгы эше турында хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2015 елгы эше турында хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Хисап палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

тышкы дәүләт финанс контроле рәвешләрен алга таба камилләштерү эшен дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына һәм алардагы үзгәрешләргә финанс-икътисадый экспертиза

уздыру, программа чараларын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган бюджет чыгымнарын тикшереп тору эшен дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчаларын нәтиҗәле куллануга аудит үткәрү эшен дәвам итәргә;

бюджет кредитлары һәм Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләрен үз вакытында үтәүне, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән кредитларны үз вакытында кире кайтаруны тикшереп торырга;

Татарстан Республикасында бюджет процессының 2016 ел дәвамында үз көченә керә торган бюджет законнарындагы үзгәрешләргә туры килүен тикшереп торуны тәэмин итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1202-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 307. «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарын гамәлгә куючылар — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарының гамәлгә куючылары вәкаләтләренең бер өлешен «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына тапшыру турындагы шартнамәләр хакында

«Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарының эшчәнлеген камилләштерү һәм эш нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Ватаным Татарстан» газетасының гамәлгә куючылары вәкаләтләренең бер өлешен «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына тапшыру турында шартнамә төзергә (1 нче кушымта).

2. «Республика Татарстан» газетасының гамәлгә куючылары вәкаләтләренең бер өлешен «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына тапшыру турында шартнамә төзергә (2 нче кушымта).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1203-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2016 елның 21 апрелендәге
1203-V ДС номерлы карарына
1 нче кушымта

**«Ватаным Татарстан» газетасын гамәлгә куючылар — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында «Ватаным Татарстан» газетасының гамәлгә куючылары вәкаләтләренең бер өлешен «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына тапшыру турында**
**ШАРТНАМӘ**

Казан шәһәре                    2016 елның ___________

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның исеменнән Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Рәис Мөхәммәтшин Фәрит Хәйрулла улы эш йөртә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, аның исеменнән «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Премьер-министр Халиков Илдар Шәүкәт улы эш йөртә, алга таба бергә «Гамәлгә куюда катнашучылар» дип аталачаклар, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, аның исеменнән «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 24 октябрендәге

902 номерлы карары нигезендә «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Зарипов Айрат Ринат улы эш йөртә, алга таба «Агентлык» дип аталачак, түбәндәгеләр хакында шартнамә төзеделәр.

### 1. Шартнамә предметы

1.1. Гамәлгә куюда катнашучылар «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт бюджет учреждениесе ризалыгы белән «Ватаным Татарстан» иҗтимагый-сәяси газетасын чыгару буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен Агентлыкка тапшыралар һәм аның үтәлешен тикшереп торалар.

1.2. Агентлык әлеге шартнамә шартлары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үз исеменнән һәм Гамәлгә куюда катнашучылар мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашыра.

### 2. Агентлыкка тапшырыла торган вәкаләтләр

2.1. «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124/1 номерлы Россия Федерациясе Законының 18 статьясы нигезендә Гамәлгә куюда катнашучылар Агентлыкка түбәндәге вәкаләтләрне тапшыралар:

- Гамәлгә куюда катнашучылар тарафыннан расланган дәүләт йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итү;
- дәүләт ихтыяҗлары өчен сатып алулар башкару;
- күчемсез мөлкәт, автотранспорт чаралары сатып алуны килештерү;
- автотранспорт чараларын гамәлдән чыгаруны килештерү;
- баш мөхәррир ялының вакытын һәм озынлыгын килештерү;
- Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары өчен Агентлык тарафыннан үткәрелә торган чараларда баш мөхәррирнең катнашуын тәэмин итү.

2.2. Агентлык күрсәтелгән вәкаләтләрне кайсы да булса өченче затка тапшырырга хокуксыз.

### 3. Гамәлгә куюда катнашучыларның һәм Агентлыкның бурычлары

3.1. Гамәлгә куюда катнашучылар түбәндәге бурычларны үтәү йөкләмәсен ала:

- Агентлыкка тапшырылган вәкаләтләрнең Агентлык тарафыннан үтәлешен тикшереп тору;



- тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлеше турында Агентлыкның еллык хисабын кабул итеп алу, аны карау һәм раслау.

3.2. Агентлык түбәндәге бурычларны үтәү йөкләмәсен ала:

- әлеге шартнамәнең 2.1 пунктында каралган вәкаләтләрне үтәү;
- Гамәлгә куюда катнашучыларга үзенә тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлеше турында еллык хисап бирү;
- Гамәлгә куюда катнашучыларга, аларның таләпләре буенча, үзенә тапшырылган вәкаләтләрне үтәү барышы турында барлык белешмәләрне хәбәр итү;
- вәкаләтләрне башкару өчен аңа тапшырылган документларның, матди кыйммәтләрнең һәм акчаларның саклanышы өчен җаваплы булу.

### 4. Йомгаклау нигезләмәсе

4.1. Әлеге шартнамә вакыты билгеләнмәгән срокка төзелде һәм аңа имза салган вакыттан үз көченә керә. Шартнамә өч нөсхәдә төзелде, алар бер үк юридик көчкә ия.

4.2. Шартнамә, әлеге шартнамәнең яклары белән килештерелеп, үзгәртелергә яисә өзелергә мөмкин.

4.3. Әлеге шартнамәне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган барлык бәхәсләр Россия Федерациясе законнары нигезендә шартнамәнең яклар тарафыннан хәл ителә.

### 5. Шартнамә якларының имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Дәүләт Советы Рәисе | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры |
| __________ Ф.Х.Мөхәммәтшин | ___________И.Ш. Халиков |

«Татмедиа» Республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы җитәкчесе

________________ А.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2016 елның 21 апрелендәге
1203-V ДС номерлы карарына
2 нче кушымта

**«Республика Татарстан» газетасын гамәлгә куючылар – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында «Республика Татарстан» газетасының гамәлгә куючылары вәкаләтләренең бер өлешен «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына тапшыру турында**
**ШАРТНАМӘ**

Казан шәһәре 2016 елның ___________

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның исеменнән Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Рәис Мөхәммәтшин Фәрит Хәйрулла улы эш йөртә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, аның исеменнән «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Премьер-министр Халиков Илдар Шәүкәт улы эш йөртә, алга таба бергә «Гамәлгә куюда катнашучылар» дип аталачаклар, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, аның исеменнән «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 24 октябрендәге 902 номерлы карары нигезендә «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Зарипов Айрат Ринат улы эш йөртә, алга таба «Агентлык» дип аталачак, түбәндәгеләр хакында шартнамә төзеделәр.

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Гамәлгә куюда катнашучылар «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт бюджет учреждениесе ризалыгы белән «Республика Татарстан» иҗтимагый-сәяси газетасын чыгару буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен Агентлыкка тапшыралар һәм аның үтәлешен тикшереп торалар.

1.2. Агентлык әлеге шартнамә шартлары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үз исеменнән һәм Гамәлгә куюда катнашучылар мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашыра.



## 2. Агентлыкка тапшырыла торган вәкаләтләр

2.1. «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124/1 номерлы Россия Федерациясе Законының 18 статьясы нигезендә Гамәлгә куюда катнашучылар Агентлыкка түбәндәге вәкаләтләрне тапшыралар:

- Гамәлгә куюда катнашучылар тарафыннан расланган дәүләт йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итү;
- дәүләт ихтыяҗлары өчен сатып алулар башкару;
- күчемсез мөлкәт, автотранспорт чаралары сатып алуны килештерү;
- автотранспорт чараларын гамәлдән чыгаруны килештерү;
- баш мөхәррир ялының вакытын һәм озынлыгын килештерү;
- Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары өчен Агентлык тарафыннан үткәрелә торган чараларда баш мөхәррирнең катнашуын тәэмин итү.

2.2. Агентлык күрсәтелгән вәкаләтләрне кайсы да булса өченче затка тапшырырга хокуксыз.

## 3. Гамәлгә куюда катнашучыларның һәм Агентлыкның бурычлары

3.1. Гамәлгә куюда катнашучылар түбәндәге бурычларны үтәү йөкләмәсен ала:

- Агентлыкка тапшырылган вәкаләтләрнең Агентлык тарафыннан үтәлешен тикшереп тору;
- тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлеше турында Агентлыкның еллык хисабын кабул итеп алу, аны карау һәм раслау.

3.2. Агентлык түбәндәге бурычларны үтәү йөкләмәсен ала:

- әлеге шартнамәнең 2.1 пунктында каралган вәкаләтләрне үтәү;
- Гамәлгә куюда катнашучыларга үзенә тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлеше турында еллык хисап бирү;
- Гамәлгә куюда катнашучыларга, аларның таләпләре буенча, үзенә тапшырылган вәкаләтләрне үтәү барышы турында барлык белешмәләрне хәбәр итү;
- вәкаләтләрне башкару өчен аңа тапшырылган документларның, матди кыйммәтләрнең һәм акчаларның сакланышы өчен җаваплы булу.

### 4. Йомгаклау нигезләмәсе

4.1. Әлеге шартнамә вакыты билгеләнмәгән срокка төзелде һәм аңа имза салган вакыттан үз көченә керә. Шартнамә өч нөсхәдә төзелде, алар бер үк юридик көчкә ия.
4.2. Шартнамә, әлеге шартнамәнең яклары белән килештерелеп, үзгәртелергә яисә өзелергә мөмкин.
4.3. Әлеге шартнамәне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган барлык бәхәсләр Россия Федерациясе законнары нигезендә шартнамәнең яклар тарафыннан хәл ителә.

### 5. Шартнамә якларының имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Дәүләт Советы Рәисе | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры |
| __________ Ф.Х.Мөхәммәтшин | ___________И.Ш. Халиков |

«Татмедиа» Республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы җитәкчесе

________________ А.Р. Зарипов

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 308. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**
1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.



2. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасында сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.
3. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында әлеге федераль закон проектын караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкиле итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1204-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 309. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 151 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**
1. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 151 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.
2. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 151 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия

Федерациясе Хөкүмәтенә һәм Россия Федерациясе Югары Судына рәсми бәяләмәләр алу өчен җибәрергә.

3. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 151 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын, аңа Россия Федерациясе Хөкүмәтеннән һәм Россия Федерациясе Югары Судыннан рәсми бәяләмәләр алганнан соң, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны үтенеп, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына мөрәҗәгать итәргә.

5. Күрсәтелгән закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкил итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1205-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 310. «Россия Федерациясе Гаилә кодексына һәм Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 233 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Гаилә кодексына һәм Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 233 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертергә.

2. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасында сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

3. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында күрсәтелгән федераль закон проектын караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкилләре итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Воропаева Татьяна Васильевнаны билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1206-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 311. «Россия Федерациясе субъектлары иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 984349-6 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы тарафыннан беренче укылышта кабул ителгән «Россия Федерациясе субъектлары иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 984349-6 номерлы федераль закон проектын карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Әлеге закон проектына төзәтмәләрне кабул итәргә һәм аларны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалар эшләре комитетына кертергә.

2. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кертелгән төзәтмәләрне хуплауны үтенеп, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) органнарына җибәрергә.

3. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында әлеге закон проектына төзәтмәләрне караганда Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улына Татарстан Республикасы Дәүләт Советын тәкъдим итүне йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1207-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 312. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1006969-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чараларының велосипедта йөрүчеләр өчен полосалар, велосипедта һәм җәяү йөрүчеләр өчен юллар буенча хәрәкәте, шулай ук күрсәтелгән полосаларда туктаган һәм туктап торган өчен җаваплылык билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1006969-6 номерлы федераль закон проектын (транспорт чараларының велосипедта йөрүчеләр өчен полосалар, велосипедта һәм җәяү йөрүчеләр өчен юллар буенча хәрәкәте, шулай ук күрсәтелгән полосаларда туктаган һәм туктап торган өчен җаваплылык билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1208-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 313. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына төзелеш объектларында чит ил эшче көчләрен законсыз җәлеп итүне һәм алардан файдалануны булдырмау максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 1015753-6 номерлы федераль закон проекты турында (заказчы (төзүче) яисә подрядчы (генераль подрядчы) функцияләрен гамәлгә ашыручы йә Россия Федерациясендә төзелеш объектларын башкача тикшереп торучы затларның мондый объектларда чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның законсыз булуы һәм законсыз хезмәт эшчәнлеге өчен административ җаваплылыгын билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына төзелеш объектларында чит ил эшче көчләрен законсыз җәлеп итүне һәм алардан файдалануны булдырмау максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 1015753-6 номерлы федераль закон проектын (заказчы (төзүче) яисә подрядчы (генераль подрядчы) функцияләрен гамәлгә ашыручы йә Россия Федерациясендә төзелеш объектларын башкача тикшереп торучы затларның мондый объектларда чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның законсыз булуы һәм законсыз хезмәт эшчәнлеге өчен административ җаваплылыгын билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1209-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 314. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1013569-6 номерлы федераль закон проекты турында (яктылыкны үткәрүгә тәгәрмәчле транспорт чараларының иминлеге хакындагы техник регламент таләпләренә туры килми торган пыялаларны транспорт чараларына куйган өчен җаваплылык билгеләү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1013569-6 номерлы федераль закон проектын (яктылыкны үткәрүгә тәгәрмәчле транспорт чараларының иминлеге хакындагы техник регламент таләпләренә туры килми торган пыялаларны транспорт чараларына куйган өчен җаваплылык билгеләү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1210-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 315. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1017410-6 номерлы федераль закон проекты турында ($19.7^7$ статьяда каралган хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тарту вакытын арттыру, шулай ук күрсәтелгән хокук бозулар буенча административ тикшерүне үткәрү мөмкинлеген билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1017410-6 номерлы федераль закон проектын ($19.7^7$ статьяда каралган хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тарту вакытын арттыру, шулай ук күрсәтелгән хокук бозулар буенча административ тикшерүне үткәрү мөмкинлеген билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1211-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 316. «Россия Федерациясенә Кырым Республикасын кабул итүгә һәм Россия Федерациясе составында яңа субъектлар — Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре төзелүгә бәйле рәвештә мәгариф өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 1010317-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Кырым Республикасы оешмаларының мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын һәм укуны тәмамлаучыларга белем алу турында документлар бирү хокукын регламентлый торган рөхсәт бирү документларының гамәлдә булуын тану срокларын 2018 елның 1 сентябренә кадәр озайту өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясенә Кырым Республикасын кабул итүгә һәм Россия Федерациясе составында яңа субъектлар — Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре төзелүгә бәйле рәвештә мәгариф өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында һәм

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 1010317-6 номерлы федераль закон проектын (Кырым Республикасы оешмаларының мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын һәм укуны тәмамлаучыларга белем алу турында документлар бирү хокукын регламентлый торган рөхсәт бирү документларының гамәлдә булуын тану срокларын 2018 елның 1 сентябренә кадәр озайту өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1212-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 317. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.



2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1213-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 318. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 32 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 32 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышына – Корыл-таена җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1214-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**319. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 50 статьясына һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль законның 154 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 1004120-6 номерлы федераль закон проекты хакында (муниципаль район белән авыл җирлекләре арасында муниципаль мөлкәт бүлешү тәртибен ачыклау өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 50 статьясына һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль законның 154 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 1004120-6 номерлы федераль закон проектын (муниципаль район белән авыл җирлекләре арасында муниципаль мөлкәт бүлешү тәртибен ачыклау өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1215-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**320. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 16 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1000387-6 номерлы федераль закон проекты турында (граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт узуга бәйле чикләүләр өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 16 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1000387-6 номерлы федераль закон проектын (граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт узуга бәйле чикләүләр өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1216-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**321. «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» Федераль законның 47 статьясына үзгәреш кертү хакында» 993118-6 номерлы федераль закон проекты турында (торак фондын техник исәпкә алу өлкәсендә норматив хокукый актларның гамәлдә булуын саклап калу өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» Федераль законның 47 статьясына үзгәреш кертү хакында» 993118-6 номерлы федераль закон проектын (торак фондын техник исәпкә

алу өлкәсендә норматив хокукый актларның гамәлдә булуын саклап калу өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1217-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 322. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 38 һәм 44 статьяларына һәм «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мәскәү өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 38 һәм 44 статьяларына һәм «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мәскәү өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Мәскәү өлкә Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1218-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 323. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 136 статьясына үзгәреш кертү хакында» 997875-6 номерлы федераль закон проекты турында (отпуск өчен түләү срокларын төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 136 статьясына үзгәреш кертү хакында» 997875-6 номерлы федераль закон проектын (отпуск өчен түләү срокларын төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1219-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 324. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Хакасия Республикасы Югары Советының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Хакасия Республикасы Югары Советының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Хакасия Республикасы Югары Советына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1220-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 325. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 статьясына һәм 14.53 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карачай-Черкес Республикасы Халык Собраниесенең (Парламентының) закон чыгару инициативасы турында (насвай, суыра торган тәмәкене (снюс) күпләп яисә ваклап, шул исәптән балигъ булмаганнарга, саткан өчен җаваплылыкны катгыйландыру өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 статьясына һәм 14.53 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карачай-Черкес Республикасы Халык Собраниесенең (Парламентының) закон чыгару инициативасын (насвай, суыра торган тәмәкене (снюс) күпләп яисә ваклап, шул исәптән балигъ булмаганнарга, саткан өчен җаваплылыкны катгыйландыру өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1221-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 326. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 1.3.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 1.3.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1222-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 327. «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 987876-6 номерлы федераль закон проекты турында (бурычлының Россия Федерациясеннән китүенә вакытлыча чикләү билгеләү мөмкинлеге өчен критерийларны төгәлләштерү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 987876-6 номерлы федераль закон проектын (бурычлының Россия Федерациясеннән китүенә вакытлыча чикләү билгеләү мөмкинлеге өчен критерийларны төгәлләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1223-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 328. «Тиешле срокта суд эшчәнлегенә хокукны яисә тиешле срокта суд актын үтәүгә хокукны бозган өчен компенсация турында» Федераль законга дәүләт тарафыннан мөлкәти һәм (яисә) мөлкәти булмаган характердагы таләпләрнең үтәлешен күздә тотучы суд актын тиешле срокта үтәү хокукын бозган өчен компенсация билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1027679-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Тиешле срокта суд эшчәнлегенә хокукны яисә тиешле срокта суд актын үтәүгә хокукны бозган өчен компенсация турында» Федераль законга дәүләт тарафыннан мөлкәти һәм (яисә) мөлкәти булмаган характердагы таләпләрнең үтәлешен күздә тотучы суд актын тиешле срокта үтәү хокукын бозган өчен компенсация билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1027679-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1224-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 329. «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында» 1037356-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында» 1037356-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1225-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 330. «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» 1037366-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» 1037366-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1226-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 331. «Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнешен контрольдә тоту өлкәсендә һәм миграция өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1037367-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнешен контрольдә тоту өлкәсендә һәм миграция өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1037367-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1227-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 332. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 333[38] статьясына үзгәреш кертү турында» 1037372-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең варисларын нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасын түләүдән азат итү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 333[38] статьясына үзгәреш кертү турында» 1037372-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең варисларын нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасын түләүдән азат итү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 21 апреле
№ 1228-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 333. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унҗиденче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унҗиденче утырышын 2016 елның 21 апрелендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2016 елның 14 апреле
№ 1158-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 334. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унҗиденче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унҗиденче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2015 елгы эшчәнлеге турында хисап.

4. «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 213-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).



5. «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 189-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

6. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 190-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

7. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 191-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

8. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 192-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

9. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында» 205-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

10. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 178-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

11. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 201-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

12. «Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 185-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

13. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 217-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 221-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 34 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 218-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 210-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 216-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм $8^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 203-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 215-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

20. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 164-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

21. Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2015 елгы эше турында хисап.

22. «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарын гамәлгә куючылар – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасындагы шартнамәләр турында – «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарын гамәлгә куючылар вәкаләтләренең бер өлешен «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына бирү турында.

23. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

24. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 151 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

25. «Россия Федерациясе Гаилә кодексына һәм Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 233 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.



26. «Россия Федерациясе субъектлары иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 984349-6 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында.

27. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1006969-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чараларының велосипедта йөрүчеләр өчен полосалар, велосипедта һәм җәяү йөрүчеләр өчен юллар буенча хәрәкәте, шулай ук күрсәтелгән полосаларда туктаган һәм туктап торган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына төзелеш объектларында чит ил эшче көчләрен законсыз җәлеп итүне һәм алардан файдалануны булдырмау максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 1015753-6 номерлы федераль закон проекты турында (заказчы (төзүче) яисә подрядчы (генераль подрядчы) функцияләрен гамәлгә ашыручы йә Россия Федерациясендә төзелеш объектларын башкача тикшереп торучы затларның мондый объектларда чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның законсыз булуы һәм законсыз хезмәт эшчәнлеге өчен административ җаваплылыгын билгеләү хакында).

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1013569-6 номерлы федераль закон проекты турында (яктылыкны үткәрүе тәгәрмәчле транспорт чараларының иминлеге хакындагы техник регламент таләпләренә туры килми торган пыялаларны транспорт чараларына куйган өчен җаваплылык билгеләү турында).

30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1017410-6 номерлы федераль закон проекты турында (19.77 статьяда каралган хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тарту вакытын арттыру, шулай ук күрсәтелгән хокук бозулар буенча административ тикшерүне үткәрү мөмкинлеген билгеләү хакында).

31. «Россия Федерациясенә Кырым Республикасын кабул итүгә һәм Россия Федерациясе составында яңа субъектлар – Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре төзелүгә бәйле рәвештә мәгариф өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 1010317-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Кырым Республикасы оешмаларының мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын һәм укуны тәмамлаучыларга белем алу турында документлар бирү хокукын регламентлый

торган рөхсәт бирү документларының гамәлдә булуын тану срокларын 2018 елның 1 сентябренә кадәр озайту өлешендә).

32. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

33. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 32 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

34. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 50 статьясына һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль законның 154 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 1004120-6 номерлы федераль закон проекты хакында (муниципаль район белән авыл җирлекләре арасында муниципаль мөлкәт бүлешү тәртибен ачыклау өлешендә).

35. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 16 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1000387-6 номерлы федераль закон проекты турында (граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт узуга бәйле чикләүләр өлешендә).

36. «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» Федераль законның 47 статьясына үзгәреш кертү хакында» 993118-6 номерлы федераль закон проекты турында (торак фондын техник исәпкә алу өлкәсендә норматив хокукый актларның гамәлдә булуын саклап калу өлешендә).

37. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 38 һәм 44 статьяларына һәм «Россия Федерациясе субъектларының



һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мәскәү өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

38. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 136 статьясына үзгәреш кертү хакында» 997875-6 номерлы федераль закон проекты турында» (отпуск өчен түләү срокларын төгәлләштерү өлешендә).

39. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Хакасия Республикасы Югары Советының закон чыгару инициативасы турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2016 елның 14 апреле
№ 1159-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 335. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты каршындагы Эксперт советы составы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты каршында Эксперт советы булдырырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты каршындагы Эксперт советы составын расларга (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2016 елның 14 апреле
№ 1161-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2016 елның 14 апрелендәге
1161-V ДС номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты каршындагы
Эксперт советы составы

| | |
|---|---|
| Паймухин Валентин Борисович | «Россия юристлары ассоциациясе» гомумросссия иҗтимагый оешмасының Татарстан региональ бүлекчәсе Аппараты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының граждан җәмгыяте институтларын үстерү, иҗтимагый советлар белән үзара эшчәнлек комиссиясе рәисе, Эксперт советы рәисе (килешү буенча) |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары, Эксперт советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Айдаров Марат Илдар улы | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе полиция башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Бартенев Артем Геннадьевич | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының гражданнарның хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Какохо Тимур Геннадьевич | «Россия юристлары ассоциациясе» гомумросссия иҗтимагый оешмасы Татарстан региональ бүлекчәсенең Яшь юристлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Рәхимов Рифат Нурмөхәммәт улы | Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм федераль регистр алып бару, муниципаль берәмлекләр реестрын алып бару, муниципаль берәмлек уставларын теркәү һәм реестрын алып бару мәсьәләләре бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Синякова Галина Юрьевна | Татарстан Республикасы Прокурорының өлкән ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Хәбибуллина Гөлнара Рушан кызы | Казан федераль университеты юридик факультетының конституциячел һәм административ хокук кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| Гончарова Злата Вячеславовна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенең баш киңәшчесе |



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 336. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты каршындагы Эксперт советы составы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты каршында Эксперт советы булдырырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты каршындагы Эксперт советы составын расларга (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2016 елның 14 апреле
№ 1162-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2016 елның 14 апрелендәге
1162-V ДС номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты каршындагы
Эксперт советы составы

| | |
|---|---|
| Баһаутдинова Наилә Гомәр кызы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт мәгариф учреждениесенең Идарә һәм территориаль үсеш институты директоры, икътисад фәннәре докторы, профессор, Эксперт советы рәисе (килешү буенча) |
| Никифоров Сергей Леонидович | «Компания ФБК Поволжье» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, «Профессиональ аудиторлар институты» коммерциягә карамаган партнерлыгының мөстәкыйль җайга салына торган аудиторлар оешмасының Урта-Идел территориаль институты (филиалы) директоры, Эксперт советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Аксянова Анна Владимировна | «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесенең «Икътисадта бизнес-статистика һәм математик ысуллар» кафедрасы мөдире, икътисад фәннәре докторы, доцент (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Клычова<br>Гүзәлия Салих кызы | «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесенең «Бухгалтерлык хисабы һәм аудит» кафедрасы мөдире, икътисад фәннәре докторы, профессор (килешү буенча) |
| Крамин<br>Тимур Владимирович | «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты» югары һөнәри белем бирү шәхси мәгариф учреждениесенең корпоратив идарә буенча проректоры, «Финанс менеджменты» кафедрасы мөдире, икътисад фәннәре докторы, профессор (килешү буенча) |
| Усманов<br>Рәис Алимҗан улы | Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсенең Татарстан Республикасы буенча Милли банкы – бүлек идарәчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Хоменко<br>Вадим Васильевич | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, икътисад фәннәре докторы, профессор (килешү буенча) |
| Абрамова<br>Ирина Юрьевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенең баш консультанты |

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 337. Ф.Х. Мөхәммәтшинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2016 елның 14 апреле
№ 1163-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 338. М.Һ. Галиевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе урынбасары Марат Һади улы Галиевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2016 елның 14 апреле
№ 1164-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 339. Ш.Ш. Яһудинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе Шакир Шәяхмәт улы Яһудинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2016 елның 14 апреле
№ 1165-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 340. Д.С. Дәүләтшинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Дания Салих кызы Дәүләтшинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2016 елның 14 апреле
№ 1166-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 341. Б.Л. Железновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры Борис Леонидович Железновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
